**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 гыйнвар № 34

г. Казань

«Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы «Рәхәт» халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен, аңарга «Зеленодольск муниципаль районындагы «Чишмә» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең территориаль үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен кушу рәвешендә, үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы «Рәхәт» халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен (алга таба – «Рәхәт» халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплекслы үзәге»), аңарга « Зеленодольск муниципаль районындагы «Чишмә» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең территориаль үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен (алга таба – «Чишмә» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең территориаль үзәге») кушу рәвешендә, «Рәхәт» халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплекслы үзәге» эшчәнлегенең төп максатларына «Чишмә» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең территориаль үзәге» эшчәнлегенең төп максатларын өстәп, үзгәртеп оештыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Рәхәт» халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплекслы үзәге» нигезендә гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлеге төзергә.

3. «Рәхәт» халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплексلы үзәге»н гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

90 көн эчендә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыру белән бәйле законнарда каралган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

юридик затларның бердәм дәүләт реестрына «Чишмә» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең территориаль үзәге» эшчәнлеге туктатылу турында язу кертелгәннән соң 60 көн эчендә «Рәхәт» халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплекслы үзәге» уставына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтен, шул исәптән оператив идарә итү хокукында «Чишмә» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең территориаль үзәге» беркетелгән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле мөлкәтне киләчәктә куллану турында тәкъдимнәр тапшырырга;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыру белән бәйле чаралар нәтиҗәсендә эштән чыгарылган хезмәткәрләргә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар өлешендә «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча каралган акча кысаларында әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыру чараларын үткәрүгә чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 60 көн эчендә элек «Чишмә» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең территориаль үзәге»нә беркетелгән Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтен законнарда билгеләнгән тәртиптә «Рәхәт» халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплекслы үзәге»нә тапшыруны тәэмин итәргә.

6. «Рәхәт» халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплекслы үзәге» тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар өлешендә «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\34.docx